**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

12.02.2016 Яр Чаллы № 372

Тукай муниципаль районы территориясендә
«Торак-2016» күзәтчелек-профилактика операциясен
үткәрү турында

Торак фондта янгыннарны һәм аларда кешеләр һәлак булуны кисәтү максатыннан,

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2016 елның гыйнвар-декабрь айларында «Торак – 2016» күзәтчелек-профилактика операциясе үткәрергә.
2. Муниципаль районның авыл җирлекләре башлыкларына һәм торак оешмалары җитәкчеләренә капиталь һәм агымдагы ремонт кысаларында янгынга каршы чараларны үтәүгә өстәмә акча җыю мәсьәләсе буенча күп фатирлы йортларда яшәүчеләрнең гомуми җыелышларын оештыруны тәкъдим итәргә.
3. Муниципаль районның авыл җирлекләре башлыкларына, мич ягып җылытканда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу сәбәпле, янгыннарны кисәтү максатыннан, «ВДПО» Яр Чаллы шәһәр бүлеге вәкилләре һәм муниципаль районның күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең янгын күзәтчелеге буенча дәүләт инспекторлары белән берлектә, район торак пунктларының шәхси торак секторының мичләрне тикшерүне оештырырга тәкъдим итәргә. Кирәк булган очракта ялгыз, өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларның шәхси торак йортларында мичләрне бушлай ремонтлау мәсьәләсен карарга.
4. Авыл җирлекләре башлыкларына, муниципаль районның торак оешмалары һәм хуҗалыклары җитәкчеләренә, муниципаль районның энергия күзәтчелеге хезмәтләре һәм кызыксынган хезмәтләре вәкилләре белән берлектә, район территориясендә торак пунктларның шәхси торак секторы электр җиһазларының торышын комиссия тикшерүе үткәрүне оештырырга тәкъдим итәргә.
5. Авыл җирлекләре башлыкларына һәм муниципаль район хуҗалыклары җитәкчеләренә җылытыла торган гаражларда һәм җайлаштырылган биналарда, төзек янгын сүндерү һәм янгын сүндерү техникасы белән, кешеләрне, мөлкәтне эвакуацияләү, янгыннарны сүндерү буенча беренчел чаралар күрү өчен, «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 нче отряды»ФДКУнең шәһәр бүлекчәләре килеп җиткәнче, тәүлек әйләнәсе кизү торуны оештырырга тәкъдим итәргә. Шулай ук Яр Чаллы шәһәренең Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә – 01 (ЕДДС-01) бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә җирле үзидарә органнарының һәм хуҗалыкларның (аерым алганда: янгын һәм җайлаштырылган техниканың төзеклеге, машина йөртүче һәм ягулыкның булуы) иректе (муниципаль)

янгын формированиеләренең сугышчан әзерлеге турында белешмәләрне көн саен шәхси контрольгә алуны тәкъдим итәргә. Янгын формированиеләренең техникасын куллануны катгый тыелырга тиеш түгел.

6. Торак пунктларның торак фондының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үткәрелгән чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне массакүләм мәгълүмат чараларында («Якты Юл», «Светлый Путь»), теле-һәм радиоканалларда яктыртуны оештырырырга.

7. Авыл җирлекләре башлыкларына, торак оешмалары һәм муниципаль район хуҗалыклары җитәкчеләренә янгынга каршы пропаганда үткәрүне, шулай ук яшәү урыны буенча халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларына аңлату эшләре алып баручы вазыйфаи затларны һәм затларны Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре буенча министрлыгы боерыгы нигезендә янгын-техник минимум программасы буенча өйрәтүне тәкъдим итәргә.

8. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф мәсьәләләре буенча урынбасары Р.Р. Исаевка уку процессында тормыш иминлеге нигезләре дәресләрен оештырырга һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен өйрәтергә тәкъдим итәргә.

9. Карарны авыл җирлекләре башлыкларына, Тукай муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

10. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев